**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021елның «20» декабреннән № 525

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11декабрендәге 323 нче номерлы карары белән расланган «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11декабрендәге 323 нче номерлы карары белән расланган «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Программаны финанс белән тәэмин итү» турындагы 6 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 2 пунктчаны өстәргә: Спорт төрләре буенча спорт әзерлеге буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү, әлеге учреждениеләрдә шөгыльләнүче спорт

объектларының террорчылыктан саклануын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешендә 2021 елга финанс чыгымнары:

| | |
|---|---|
| Физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрнең муниципаль йөкләмәсен үтәү максатларында спорт объектларының террорчылыктан саклануын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешендә спорт төрләре буенча спорт әзерлеге буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү (республика бюджеты) | 247,7 |
| Физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрнең муниципаль йөкләмәсен үтәү максатларында спорт объектларының террорчылыктан саклануын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешендә спорт төрләре буенча спорт әзерлеге буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү (җирле бюджет 1%) | 2477,0 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р. Р. Фасахов